**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**20.08.2021** **№ 727**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 16 декабрендәге 944 номерлы «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районының балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствоара комиссиясенең 2021 елның 10 августындагы карары нигезендә, 2021 елгы мәктәп каникуллары чорында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру, аларның мәшгульлеген тәэмин итү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 16 декабрендәге 944 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» ярдәмче программасының 3 нче кушымтасында балаларны һәм яшьләрнең ялын оештыруга хезмәт күрсәтүләр күләмнәре нормативларын яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча халыкка җиткерергә һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтына: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 20 августындагы
727 номерлы карарына
кушымта

**БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ОЕШТЫРУГА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЛӘР
КҮЛӘМНӘРЕНЕҢ НОРМАТИВЛАРЫ**

| Балалар һәм яшьләр категориясе аталышы | Сменаны оештыручы | Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерелүен оештыру формасы | Саны, кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Иҗади яктан сәләтле яисә социаль актив балалар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ | палаткалы лагерьда профильле смена | 100 |
| Гомуми белем бирү оешмалары укучылары | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МКУ | көндезге лагерьда смена | 700 |
| | | хезмәт һәм ял лагеренда смена | 300 |
| | | көндезге лагерьда смена (мәктәп яны) | 450 |
| Муниципаль һәм дәүләт | «Татарстан | стационар лагерьда | 300 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| оешмалары хезмәткәрләренең балалары | Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ | смена | |
| Коммерцияле һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең балалары (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ | стационар лагерьда смена | 5 |
| Иҗади сәләтле яисә социаль актив балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МКУ | стационар лагерьда профильле смена | 200 |
| | | стационар лагерьда профильле смена | 200 |
| | | Барлыгы: | 2255 |